Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Олы Елга авыл җирлеге Советы

**КАРАР № LV-1**

Олы Елга авылы

2019 елның 14 феврале

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлеге Советының 2016 елның 26 декабрендәге XXVI-1 номерлы карары белән расланган “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Олы Елга авыл җирлеге”муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында”Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлеге Советының карар проекты хакында

2003 елның 6 октябрендәге “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 маддәсенең 2 өлеше нигезендә, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының “Олы Елга авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлеге Советының 2016 елның 26 декабрендәге XXVI-1 номерлы карары белән расланган “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Олы Елга авыл җирлеге” муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында” Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлеге Советының карар проектын хупларга һәм ачык (гавами) тыңлауларга чыгарырга (кушымта №1).

2.Расларга:

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлеге Советының 2016 елның 26 декабрендәге XXVI-1 номерлы карары белән расланган “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Олы Елга авыл җирлеге” муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында” Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлеге Советының карар проекты буенча гражданнарның тәкъдимнәрен исәпкә алу Тәртибен (кушымта №2).

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлеге Советының 2016 елның 26 декабрендәге XXVI-1 номерлы карары белән расланган “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Олы Елга авыл җирлеге” муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында” Татарстан Республикасы Балык

Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлеге Советының карар проекты буенча ачык (гавами) тыңлаулар уздыру Тәртибен (кушымта №3).

3.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлеге Советының "Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы "Олы Елга авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында" Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлеге Советының карар проекты буенча ачык (гавами) тыңлауларны 2019 елның 15 апреле көнне 11.00 сәгатькә түбәндәге адрес буенча билгеләргә: ТР, Балык Бистәсе районы, Олы Елга авылы, Октябрь урамы, 25 йорт.

4.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлеге Советының 2016 елның 26 декабрендәге XXVI-1 номерлы карары белән расланган "Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы "Олы Елга авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында" Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлеге Советының карар проекты буенча кергән тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча түбәндәге составта эшче төркем төзергә:

Садриев Фәрит Әмирхан улы – Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлеге Башлыгы, эшче төркем рәисе;

Миннегәлиева Гөлнур Мансур кызы – Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлегенең 2 номерлы сайлау округы депутаты, оештыру комитеты әгъзасы;

Габдуллина Гөлфинур Хәмитҗан кызы – Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлегенең 6 номерлы сайлау округы депутаты, эшче төркем сәркатибе.

5. Эшче төркемгә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлеге Советының 2016 елның 26 декабрендәге XXVI-1 номерлы карары белән расланган "Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы "Олы Елга авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында" Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлеге Советының карар проекты буенча ачык тыңлауларда әйтелгән һәм аның буенча фикер алышу барышында кергән тәкъдимнәрне исәпкә алып, карар проектын эшләп бетерергә һәм икенче укылышта карау өчен Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлеге Советы каравына кертүне тәэмин итәргә.

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлегенең Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Олы Елга авылы, Октябрь урамы, 25 нче йорт; Казаклар авылы, Үзәк урам, 9 нчы йорт; Саескан Тавы авылы, Үзәк урам, 16А йорт; Кама поселогы, Курортная-2 урамы, 23 йорт адреслары буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтындаһәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы"нда урнаштырырга.

7. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Олы Елга авыл җирлеге башлыгы Ф.Ә.Садриев

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Олы Елга авыл җирлеге Советының
2019 елның14 февралендәге
LV-1номерлы карарына
кушымта №1

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлеге Советының 2016 елның 26 декабрендәге XXVI-1 номерлы карары белән расланган “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Олы Елга авыл җирлеге” муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында” Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлеге Советы карар проекты

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Олы Елга авыл җирлеге” муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында мәгълүматны тыңлап тикшергәннән соң,җирдән файдалану һәм төзелеш эшләрен җайга салу тәртибен камилләштерү максатларында,Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, Россия Федерациясе Җир кодексы, 2003 елның 6 октябрендәге “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының “Олы Елга авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, 2019 елның 15 апрелендә уздырылган ачык (гавами) тыңлауларның нәтиҗәләрен исәпкә алып,Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлеге Советының 2016 елның 26 декабрендәге XXVI-1 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Олы Елга авыл җирлеге” муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару Кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1) 14 маддәнең 7 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
““Олы Елга авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге халкына җәмәгатьчелек фикер алышулары яисә ачык тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә игълан ителгән көнгә кадәр аларны уздыру турында хәбәр иткән көннән алып җәмәгатьчелек фикер алышулары яисә ачык тыңлаулар үткәрү чоры (срогы) “Олы Елга авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставы һәм (яисә) муниципаль берәмлекнең Олы Елга авыл җирлеге Советының норматив хокукый акты белән билгеләнә һәм бер айдан артык була алмый.”

1.2)14 маддәнең 8 пунктында “ачык тыңлаулар нәтиҗәләре” сүзләрен “җәмәгатьчелек фикер алышулары яисә ачык тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә” сүзләре белән алмаштырырга;

1.3) 29 маддәнең 5 пунктындагы 6 абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

1.4) 27 маддәнең 4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
“Инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләренә экспертиза нәтиҗәсе – инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләренең техник регламентлар таләпләренә туры килүе (уңай

бәяләмә) яки туры килмәве (тискәре бәяләмә) турында бәяләмә. Проект документларына экспертиза нәтиҗәләре булып бәяләмә тора:

-проект документларының инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләренә, проектлау биременә, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5 өлешендәге 1 пунктында каралган таләпләргә туры килүе (уңай бәяләмә) яисә туры килмәве (тискәре бәяләмә) турында (Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 маддәсендәге 3.3 өлешенең 1 пункты нигезендә проект документларына экспертиза үткәрү очракларыннан тыш);

-Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 8.3 маддәсендәге 2 өлешендә билгеләнгән очракларда капиталь төзелеш объектлары төзелешенең смета бәясен билгеләүнең дөреслеге (уңай бәяләмә) яисә дөрес түгеллеге (тискәре бәяләмә) турында.";

1.5) 26 маддәнең 8 пунктында 15 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Проект документациясенең экспертизага һәм дәүләт төзелеш күзәтчелеге органнарына тапшырыла торган бүлекләренең составы һәм эчтәлегенә карата таләпләр Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә һәм капиталь төзелеш объектларының төрле төрләренә (шул исәптән линияле объектларга) карата дифференциацияләнә,шулай ук капиталь төзелеш объектларының билгеләнешенә, эш төрләренә (төзелеш, реконструкция, капиталь төзелеш объектларына капиталь ремонт), аларның эчтәлегенә, эшләрне финанслау чыганакларына һәм Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 48 маддәсе таләпләренә туры китереп һәм түбәндәге үзенчәлекләрне исәпкә алып, төзелешнең, реконструкциянең аерым этапларын аерып алуга бәйле рәвештә:

-проект документларын әзерләү капиталь төзелеш объектларының төрле төрләренә (шул исәптән линияле объектларга) карата аерым бүлекләр күләмендә гамәлгә ашырыла,шулай ук капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләгәндә башкарыла торган эшләр эчтәлегенә бәйле рәвештә проектлауга төзүче яисә техник заказчы биреме нигезендә(капиталь төзелеш объектына реконструкцияләү үткәрелгән очракта);

-капиталь төзелеш объектларын төзүне оештыру проектында капиталь төзелеш объектларын, аларның өлешләрен сүтү эшләрен оештыру проекты булырга тиеш(капиталь төзелеш объектларын, аларның өлешләрен капиталь төзелешнең башка объектларын төзү, реконструкцияләү өчен сүтү зарурлыгы булган очракта);

-проект документациясендә булган чишелешләр һәм чаралар мәдәни мирас объектларын саклау турында Россия Федерациясе законнары таләпләренә туры килергә тиеш(мәдәни мирас объектларын саклау буенча мондый объектларның ышанычлылыгы һәм куркынычсызлыгының конструкциягә караган һәм башка сыйфатламаларына кагыла торган эшләр алып бару өчен проект документациясен әзерләгән очракта);

-проект документациясе "Капиталь төзелеш объектын төзүгә, реконструкцияләүгә, капиталь ремонтлауга, сүтүгә смета" бүлеген үз эченә алырга тиеш (төзү, реконструкцияләү, сүтү Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары акчаларын, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 8.3 маддәсенең 2 өлешендә күрсәтелгән юридик затлар акчаларын җәлеп итеп финанслана торган,капиталь ремонт Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары акчаларын, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 8.3 маддәсенең 1 өлешендә күрсәтелгән затлар акчаларын җәлеп итеп финанслана торган очракларда);

-“Хәтәр производство объектларының сәнәгать иминлеге турында" 1997 елның 21 июлендәге 116-ФЗ номерлы Федераль законның 14 маддәсенең 3 пунктында, "Гидротехник корылмаларның иминлеге турында" 1997 елның 21 июлендәге 117-ФЗ номерлы Федераль законның 10 маддәсендә, "Атом энергиясеннән файдалану турында" 1995 елның 21 ноябрендәге 170-ФЗ номерлы Федераль законның 30 маддәсендә, "Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәни һәйкәлләре) турында" 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы Федераль законның 36 маддәсенең 2 һәм 3 пунктларында каралган очракларда,проект документлары составына мәҗбүри рәвештә күрсәтелгән федераль законнарда каралган документлар, проект документларының бүлекләре кертелә."

1.6) 26 маддәнең 8 пунктында 2 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Россия Федерациясе шәһәр төзелеше кодексының 48 маддәсенең 13 өлешендә каралган үзенчәлекләрне исәпкә алып, капиталь төзелеш объектларының проект документлары составына түбәндәге бүлекләр кертелә:

-капиталь төзелеш объектларын архитектура-төзелеш проектлавы, төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау өчен беренчел мәгълүматлар белән аңлатма язуы,шул исәптән инженер-техник тәэмин итү челтәрләренә тоташтыруның (технологик ялгауның) техник шартлары белән,һәм инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләренә инженерлык тикшеренүләре нәтиҗәләренә экспертизаның уңай бәяләмә реквизитлары беләнпроект документациясенә экспертиза уздырганчыга кадәр экспертиза үткәрелгән очракта;

-җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планында күрсәтелгән мәгълүмат нигезендә башкарылган җир участогын планлаштыру схемасы, ә линияле объектларга карата проект документациясе әзерләнгән очракта, территорияне планлаштыру проекты нигезендә башкарылган бүлеп бирелгән полосаның проекты(линияле объектны төзү, реконструкцияләү өчен территорияне планлаштыру буенча документлар әзерләү таләп ителми торган очраклардан гайре);

-архитектура, функциональ-технологик, конструктив, инженер-техник чишелешләр һәм (яисә) түбәндәгеләрне үтәүне тәэмин итүгә юнәлдерелгән чаралары булган бүлекләр:

а)техник регламентлар таләпләрен, шул исәптән механик, янгынга каршы һәм башка куркынычсызлык таләпләрен, энергетика нәтиҗәлелеге таләпләрен,биналарга, каралтыларга, корылмаларга карата энергия ресурсларын файдалана торган биналарга, корылмаларга исәпкә алу приборлары белән тәэмин итү таләпләрен (шул исәптән аларның составына керүче инженер-техник тәэмин итү челтәрләренә һәм системаларына),инвалидларның капиталь төзелеш объектына керүен тәэмин итү таләпләрен (сәламәтлек саклау, мәгариф, мәдәният, ял, спорт һәм социаль-мәдәни һәм коммуналь-көнкүреш билгеләнешендәге башка объектларга, транспорт, сәүдә, җәмәгать туклануы объектларына, эшлекле, административ, финанс, дини билгеләнештәге объектларга, торак фонды объектларына карата проект документациясен әзерләгәндә);

б) санитар-эпидемиологик таләпләрне, әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге таләпләр, атом энергиясен имин куллануга таләпләр, сәнәгать иминлеге таләпләре, электр энергетикасы системаларының һәм электр энергетикасы объектларының ышанычлылыгын һәм иминлеген тәэмин итүгә таләпләрне, объектларның террорчылыкка каршы яклануы таләпләрен;

в) биналарны һәм корылмаларны проектлау, төзү, монтажлау, көйләү, эксплуатацияләү процессларына таләпләрне;
г)капиталь төзелеш объектларын инженерлык-техник тәэмин итү челтәрләренә тоташтыруның (технологик ялгауның) техник шартлары таләпләрен;
-капиталь төзелешобъектларынтөзүнеоештыру проектын;

- капиталь төзелеш объектларын имин файдалануны тәэмин итүгә таләпләрне;

-капиталь төзелеш объектын куркынычсыз эксплуатацияләүне тәэмин итү өчен кирәкле капиталь төзелеш объектын капиталь ремонтлау буенча эшләрне башкаруның норматив периодиклыгы турында мәгълүматлар,шулай ук күпфатирлы йортны төзү, реконструкцияләү өчен проект документациясен әзерләү очрагында күрсәтелгән эшләрнең күләме һәм составы турында мәгълүматлар.";

1.7) 30 маддәнең 8 пунктын ", күчемсез мөлкәтнең Бердәм дәүләт реестры мәгълүматларына, шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итү буенча дәүләт мәгълүмат системаларында булган мәгълүматлар, документлар һәм материалларга" сүзләре белән тулыландырырга;

1.8) 28 маддәнең 10 пунктында "техник регламентларның" сүзләрен төшереп калдырырга, "энергетик нәтиҗәлелеген" сүзләреннән соң "(энергетика нәтиҗәлелеге таләпләре кагылмый торган капиталь төзелеш объектларыннан тыш)" сүзләрен өстәргә;

1.9) 27 маддәнең 8 пунктындагы 3 абзацта "яисә индивидуаль торак төзелеше объектын урнаштыру урынын күрсәтеп, җир кишәрлеген планлаштыру схемасы" сүзләрен һәм "яисә җир кишәрлеген планлаштыру оешмасының күрсәтелгән схемасы" сүзләрен төшереп калдырырга;

1.10)25 маддәнең 2 пунктында "гараж төзелешенең" сүзләрен "гараж төзү, реконструкцияләү" сүзләренә алыштырырга, "бакчачылык, дача хуҗалыгы алып бару өчен бирелгән җир кишәрлегендә төзелешнең" сүзләрен "бакча җир кишәрлегендә торак йорт, бакча йорты, хуҗалык корылмалары төзү, реконструкцияләү" сүзләре белән алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлектәге 2.1) пункты белән тулыландырырга:

"2.1) индивидуаль торак төзелеше объектларын төзү, реконструкцияләү;";

1.11)26 маддәнең 1 пунктында 2 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
"Шәхси торак төзелеше объектын, бакча йортын төзегәндә, реконструкцияләгәндә проект документациясе әзерләүне гамәлгә ашыру таләп ителми.Төзүче үз инициативасы буенча индивидуаль торак төзелеше объектына, бакча йортына карата проект документациясен әзерләүне тәэмин итәргә хокуклы.";

1.12) 26 маддәнең 8 пунктында 7 пунктчаның "яки сүтүгә" һәм "яки сүтүне" сүзләрен төшереп калдырырга;

1.13) 26 маддәнең 8 пунктында 10 пунктчаның "капиталь ремонт" сүзләреннән соң ",сүтү" сүзе белән тулыландырырга;

1.14)1 маддәнең 10 абзацында "капиталь ремонт" сүзләреннән соң ",сүтү" сүзе белән тулыландырырга;

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлегенең Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Олы Елга авылы, Октябрь урамы, 25 нче йорт; Казаклар авылы, Үзәк урам, 9 нчы йорт; Саескан Тавы авылы, Үзәк урам, 16А йорт; Кама поселогы, Курортная-2 урамы, 23 йорт адреслары буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-

sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет”мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”ында урнаштырырга.

3. Карар, әлеге карарның 4 пункты белән үз көченә керүнең башка вакытлары билгеләнгән нигезләмәләрдән тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлеге Советының 2016 елның 26 декабрендәге XXVI-1 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы ”Олы Елга авыл җирлеге” муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләренең 26 маддәсенең 2 пунктына, 26 маддәсе 8 пунктының 15 абзацына кертелгән үзгәрешләр 2019 елның 1 июленнән үз көченә керә.

5. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Олы Елга авыл җирлеге башлыгы

СОВЕТ БОЛЬШЕЕЛГИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ИНН 1634000235 ОЛЫ ЕЛГА АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

Ф.Ә.Садриев

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Олы Елга авыл җирлеге Советының
2019 елның14 февралендәге
LV-1 номерлы карарына
кушымта №2

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлеге Советының 2016 елның 26 декабрендәге XXVI-1 номерлы карары белән расланган "Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы "Олы Елга авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында" Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлеге Советының карар проекты буенча гражданнарның тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибе

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлеге Советының 2016 елның 26 декабрендәге XXVI-1 номерлы карары белән расланган "Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы "Олы Елга авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында" Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлеге Советының карар проекты буенча гражданнарның тәкъдимнәре язма рәвештә үрнәк нигезендә төзәтмәләр таблицасы рәвешендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлеге Советына кертелә:

| № п/п | Маддә, пункт, пунктча | Карар проекты тексты | Төзәтмә тексты | Төзәтмәне исәпкә алып проект тексты | Төзәтмә авторы (Ф.И.А.и., адрес, телефон, эш (уку) урыны) |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |

Тәкъдимнәр түбәндәге адрес (почта) буенча юллана: 422640, ТР, Балык Бистәсе районы, Олы Елга авылы, Октябрь урамы, 25 йорт яисә (88-43-61)2-52-65 факсы буенча.

Тәкъдимнәр Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлеге Советының 2016 елның 26 декабрендәге XXVI-1 номерлы карары белән расланган "Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы "Олы Елга авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында" Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлеге Советының карар проекты игълан ителгән көннән алып 2019 елның 13 апреленә чаклы эш көннәрендә 8 сәгатьтән 17 сәгатькә кадәр кабул ителә.

2. Чыгыш ясау хокукы белән ачык тыңлауларда катнашуга гаризалар түбәндәге адрес буенча бирелә: 422640, ТР, Балык Бистәсе районы, Олы Елга авылы, Октябрь урамы, 25 нче йорт; Казаклар авылы, Үзәк урам, 9 нчы йорт;

Саескан Тавы авылы, Үзәк урам, 16А йорт;  Кама  поселогы, Курортная-2 урамы, 23 йорт яисә   (88-43-61)2-52-65 факсы буенча.

Гаризалар эш көннәрендә 8 дән 17 сәг.кә чаклы  ачык тыңлаулар  үткәрелү датасына кадәр  7 көннән дә соңга калмыйча  кабул ителәләр.

3.Гражданнар тәкъдимнәре Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлеге башкарма комитеты хезмәткәрләре тарафыннан теркәлә һәм карау өчен Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлеге Советына тапшырылалар.

Татарстан Республикасы
Балык  Бистәсе муниципаль районы
Олы Елга авыл җирлеге башлыгы　　　　　　　　　　Ф.Ә.Садриев

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Олы Елга авыл җирлеге Советының
2019 елның 14 февралендәге
LV-1 номерлы карарына
кушымта №3

## Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлеге Советының 2016 елның 26 декабрендәге XXVI-1 номерлы карары белән расланган "Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы "Олы Елга авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында" Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлеге Советының карар проекты буенча ачык (гавами) тыңлаулар уздыру Тәртибе

1.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлеге Советының 2016 елның 26 декабрендәге XXVI-1 номерлы карары белән расланган "Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы "Олы Елга авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында" Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлеге Советының карар проекты буенча ачык (гавами) тыңлаулар(алга таба – ачык (гавами) тыңлаулар, тиндәшле рәвештә карар проекты)Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы "Олы Елга авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставының 19 маддәсе һәм әлеге Тәртип нигезендә үткәрелә.

2. Үзләренең тәкъдимнәрен дәлилләү өчен чыгыш ясау хокукы белән ачык тыңлауларда катнашучылар булып язма рәвештә үзләренең гаризаларын ачык тыңлаулар үткәрелү датасына хәтле җиде көннән дә соңга калмыйча җирлек Советына биргән җирлектә көн итүче кешеләр тора.

3. Ачык тыңлауларда чыгыш ясау хокукына ия булмый гына катнашучылар булып җирлекнең һәммә кызыксынучы кешесе торырга мөмкин.

4. Катнашучыларны теркәү ачык тыңлаулар башланганчы 30 минут алдан башлана.

5. Ачык тыңлауларда җирлек Башлыгы яки яның йөкләмәсе буенча авыл җирлеге Башкарма комитеты рәисе, карар проекты буенча кергән тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча эшче төркем рәисе рәислек итә.

6.Ачык тыңлаулар рәислек итүченең кереш сүзе белән башлана, ул залда булучыларга тикшерелә торган мәсьәләнең асылы, тыңлауларны үткәрү тәртибе хакында мәгълүмат ирештерә.

7. Беркетмәне рәсмиләштерү, кергән тәкъдимнәрне, киңәшләрне исәпкә алу өчен рәислек итүче тәкъдиме буенча җитәкчесе һәм ике әгъзасы составында секретариат сайлана.

8. Төп доклад белән эшче төркем әгъзасы чыгыш ясый.

9. Ачык тыңлауларның чыгыш ясау хокукына ия катнашучылары гариза бирү вакытына бәйле рәвештә чират тәртибендә үзләренең тәкъдимнәрен дәлилләү өчен чакырылалар.

10.Ачык тыңлауларда катнашучыларның чыгышлары 5 минуттан артык дәвам итәргә тиеш түгел. Рәислек итүченең рөхсәте белән чыгыш ясау вакыты озайтылырга мөмкин, әмма 3 минуттан артыкка түгел.

11.Ачык тыңлауларда катнашучылар чыгыш ясаучыларга чыгыш тәмамланганнан соң рәислек итүче рөхсәте белән сораулар бирергә хокуклы.

12. Ачык тыңлауларда катнашучылар ачык тыңлаулар барышына тыгылырга, аларны өзәргә һәм үткәрүгә комачауларга хаклы түгел.

13. Ачык тыңлауларны үткәргәндә тәртипне үтәү ачык тыңлауларда катнашу өчен мәҗбүри шарт булып тора.

14. Ачык тыңлауларда катнашучылар тарафыннан үткәрү тәртибен бозу очрагында рәислек итүче аларны залдан чыгарып җибәрүне таләп итәргә хаклы.

15.Чыгышлар төгәлләнгәннән соң рәислек итүче ачык тыңлаулар барышында әйтелгән тәкъдимнәр, киңәшләрне аныклау өчен ачык тыңлаулар секретариаты җитәкчесенә сүз бирергә мөмкин.

16. Ачык тыңлауларда катнашучыларның барлык замечание һәм тәкъдимнәре секретариатка язма рәвештә бирелә һәм ачык тыңлаулар беркетмәсенә теркәлә. Ачык тыңлаулар беркетмәсе рәислек итүче тарафыннан имзалана һәм билгеләнгән тәртиптә җирлек Советы материалларында саклана.

17. Ачык тыңлаулар йомгаклары буенча нәтиҗә (бәяләмә) эшче төркем тарафыннан әзерләнә.

18.Ачык тыңлаулар йомгаклары буенча нәтиҗә (бәяләмә) халыкка игълан ителергә тиешле.

19.Ачык тыңлауларны үткәрүнең оештыру һәм матди-техник тәэмин ителеше Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлеге Башкарма комитеты тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Олы Елга авыл җирлеге башлыгы

СОВЕТ БОЛЬШЕЕЛГИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ИНН 1634000236 ОЛЫ ЕЛГА АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

Ф.Ә.Садриев